ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.10.2020 ел Баулы шәһәре №199

Баулы муниципаль районы
«Водоканал» муниципаль казна
предприятиесе Уставына
өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының, “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, оешмалар (учреждениеләрдә) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу чаралары турында 2018 елның 1 июнендәге 10-06/8579 номерлы хатына таянып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 25 сентябрендәге 299 номерлы карары белән расланган «Водоканал» Баулы муниципаль казна предприятиесе Уставына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

8нче өлештән соң түбәндәге эчтәлекле «Мәнфәгатьләр конфликтларын булдырмау һәм җайга салу» дигән 9нчы бүлекне өстәргә:

«9. Мәнфәгатьләр конфликтларын булдырмау һәм җайга салу

9.1. Мәнфәгатьләр конфликты дигәндә хезмәткәрнең шәхси кызыксынуы аның хезмәт бурычларын тиешенчә үтәвенә йогынты ясарга мөмкин булган һәм шул вакытта Учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм ул хезмәт иткән Учреждениенең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында каршылыклар килеп чыгарырга һәм Учреждение мөлкәтенә һәм (яисә) эшлекле абруена зыян китерергә сәләтле булган хәл аңлашыла.

9.2. Хезмәттәге бурычларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясый торган яисә йогынты ясый ала торган Учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы дигәндә, Учреждение хезмәткәре тарафыннан акча, кыйммәтле әйберләр, башка мөлкәт, шул исәптән милек хокуклары, яисә мөлкәти характердагы хезмәтләр рәвешендә яисә өченче затлар өчен керемнәрне хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алу мөмкинлеге аңлашыла.

9.3. Учреждение директоры Учредительгә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш.

9.4. Учреждение хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында Учреждение директорына хәбәр итәргә тиеш. Учреждение директорына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган белешмәләр исемлеге, әлеге белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе Учреждение директоры тарафыннан билгеләнә.».

2. БМР "Водоканал" МКП Уставына нигезләмәгә үзгәрешләр кертүне салым органында теркәү буенча вәкаләтләрне "Водоканал" МКП директоры Шаймарданов Рафаэль Марселевичка тапшырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары И.И. Хөснуллинага йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаучы — И.И. Хөснуллина